**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О противодействии коррупции в Республике Татарстан»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
8 июля 2021 года

## Статья 1

Внести в Закон Республики Татарстан от 4 мая 2006 года № 34-ЗРТ «О противодействии коррупции в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2006, № 5; 2010, № 1 – 2; 2014, № 6 (II часть) следующие изменения:

1) пункт 1 статьи 1 после слов «Федеральном законе» дополнить словами «от 25 декабря 2008 года № 273-ФЗ»;

2) в статье 2:
а) в пункте 3 слова «и юридических лиц» заменить словами «лиц и организаций»;
б) в пункте 4 слова «повышение риска» заменить словом «предупреждение»;

3) в статье 3:
а) в пункте 1 слова «граждан и юридических лиц» заменить словами «физических лиц и организаций»;
б) пункт 6 после слов «государственные должности Республики Татарстан,» дополнить словами «муниципальные должности,»;

4) в статье $8^1$:
а) в пункте 1 части 1 слова «антикоррупционных программ» заменить словами «программ по реализации антикоррупционной политики»;
б) в части 2 слова «законодательством Российской Федерации» заменить словами «федеральным законодательством»;

5) в статье 9:

а) наименование изложить в следующей редакции:

«Статья 9. **Программы по реализации антикоррупционной политики**»;

б) в части 1 слова «Антикоррупционная программа» заменить словами «Программа по реализации антикоррупционной политики»;

в) в части 2 в первом предложении слова «Антикоррупционная программа Республики Татарстан» заменить словами «Государственная программа по реализации антикоррупционной политики Республики Татарстан», во втором предложении слова «антикоррупционной программы Республики Татарстан» заменить словами «соответствующей программы»;

г) часть 3 изложить в следующей редакции:

«3. Ведомственные программы по реализации антикоррупционной политики и (или) планы разрабатываются и реализуются органами исполнительной власти Республики Татарстан.»;

д) в части 4 слова «Муниципальные антикоррупционные программы» заменить словами «Муниципальные программы по реализации антикоррупционной политики», слова «законодательством Российской Федерации и Республики Татарстан об органах местного самоуправления» заменить словами «федеральным законодательством и законодательством Республики Татарстан о местном самоуправлении»;

6) в статье 10:

а) в части 2 слова «исполнительными органами государственной власти Республики Татарстан, иными органами и организациями, нормативных правовых актов исполнительных органов государственной власти Республики Татарстан, затрагивающих права, свободы и обязанности человека и гражданина, устанавливающих правовой статус организаций или имеющих межведомственный характер,» заменить словами «органами исполнительной власти Республики Татарстан, нормативных правовых актов органов исполнительной власти Республики Татарстан»;

б) в части 5 слова «Министерства, ведомства Республики Татарстан» заменить словами «Органы исполнительной власти Республики Татарстан»;

7) в статье 11:

а) в части 2 слова «Исполнительный орган государственной власти Республики Татарстан» заменить словами «Орган исполнительной власти Республики Татарстан»;

б) часть 3 изложить в следующей редакции:

«3. Решение о необходимости проведения социологических исследований общественного мнения по отдельным вопросам состояния коррупции в Республике Татарстан принимается Кабинетом Министров Республики Татарстан.»;

8) в статье 12:

а) в части 3 слова «антикоррупционных программ» заменить словами «программ по реализации антикоррупционной политики»;

б) часть 4 после слов «Законом Российской Федерации» дополнить словами «от 27 декабря 1991 года № 2124-1»;

9) в статье 14:

а) в части 1 слова «Министерства и ведомства Республики Татарстан» заменить словами «Органы исполнительной власти Республики Татарстан»;

б) в части 2 слова «антикоррупционных программ» заменить словами «программ по реализации антикоррупционной политики»;

10) в статье 15:

а) в части 1 слова «исполнительных органов государственной власти Республики Татарстан» заменить словами «органов исполнительной власти Республики Татарстан»;

б) в части 3 слова «исполнительных органов государственной власти Республики Татарстан» заменить словами «органов исполнительной власти Республики Татарстан»;

в) часть 6 дополнить словами «о противодействии коррупции»;

11) в статье 17 слова «на очередной финансовый год» исключить.

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
16 июля 2021 года
№ 48-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 8 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» 2006 елның 4 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 5; 2010, № 1 – 2; 2014, № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 1 пунктында «Федераль законда» сүзләрен «2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда» сүзләренә алмаштырырга;

2) 2 статьяда:

а) 3 пунктта «һәм юридик затларның» сүзләрен «затларның һәм оешмаларның» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 пунктта «тәртипнең хәтәр булуын һәм аннан килгән югалтуларны арттыру» сүзләрен «тәртипне һәм аның аркасындагы югалтуларны кисәтү» сүзләренә алмаштырырга;

3) 3 статьяда:

а) 1 пунктта «гражданнарның һәм юридик затларның» сүзләрен «физик затларның һәм оешмаларның» сүзләренә алмаштырырга;

б) 6 пунктта «Татарстан Республикасының дәүләт вазыйфаларын,» сүзләреннән соң «муниципаль вазыйфаларны,» сүзләрен өстәргә;

4) $8^1$ статьяда:

а) 1 өлешнең 1 пунктында «коррупциягә каршы республика, ведомство һәм муниципаль программалар» сүзләрен «коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру буенча республика программасын, ведомство программаларын һәм муниципаль программаларны» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «Россия Федерациясе законнары» сүзләрен «федераль законнар» сүзләренә алмаштырырга;

5) 9 статьяда:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9 статья. **Коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру программалары**»;

б) 1 өлештә «Коррупциягә каршы программа» сүзләрен «Коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру программасы» сүзләренә алмаштырырга;

в) 2 өлешнең беренче җөмләсендә «Татарстан Республикасының коррупциягә каршы программасы» сүзләрен «Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру буенча дәүләт программасы» сүзләренә, икенче җөмләсендә «Татарстан Республикасының коррупциягә каршы программасы» сүзләрен «Тиешле программа» сүзләренә алмаштырырга;

г) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру буенча ведомство программалары һәм (яисә) планнары Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан эшләнә һәм гамәлгә ашырыла.»;

д) 4 өлештә «Коррупциягә каршы муниципаль программалар муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртип нигезендә Татарстан Республикасы» сүзләрен «Коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру буенча муниципаль программалар җирле үзидарә турындагы федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртип нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының» сүзләренә алмаштырырга;

6) 10 статьяда:

а) 2 өлештә «Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнары, бүтән органнар һәм оешмалар тарафыннан эшләнә торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының кеше һәм гражданның хокукларына, ирегенә һәм бурычларына кагыла торган, оешмаларның хокукый статусын билгеләүче яисә ведомствоара характерга ия булган норматив хокукый актларына» сүзләрен «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан эшләнә торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларына, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актларына» сүзләренә алмаштырырга;

б) 5 өлештә «Министрлыклар, ведомстволар» сүзләрен «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләренә алмаштырырга;

7) 11 статьяда:

а) 2 өлештә «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең Татарстан Республикасында коррупциягә каршы мониторинг үткәрүгә вәкаләтле башкарма органы» сүзләрен «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан

Республикасында коррупциягә каршы мониторинг үткәрүгә вәкаләтле органы» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасында коррупция торышының аерым мәсьәләләре буенча җәмәгатьчелек фикеренә социологик тикшеренүләр үткәрү зарурлыгы турында карарны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты кабул итә.»;

8) 12 статьяда:

а) 3 өлештә «коррупциягә каршы гамәлгә ашырыла торган программалар» сүзләрен «коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру буенча башкарыла торган программалар» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә «Россия Федерациясе Законы» сүзләрен «1991 елның 27 декабрендәге 2124-1 номерлы Россия Федерациясе Законы» сүзләренә алмаштырырга;

9) 14 статьяда:

а) 1 өлештә «Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары» сүзләрен «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «коррупциячел программаларны гамәлгә ашыру» сүзләрен «коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру программаларын башкару» сүзләренә алмаштырырга;

10) 15 статьяда:

а) 1 өлештә «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының» сүзләрен «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының» сүзләрен «Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең аның ведомство буйсынуындагы органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

в) 6 өлештә «федераль законнар» сүзләрен «коррупциягә каршы көрәш турындагы федераль законнар» сүзләренә алмаштырырга;

11) 17 статьяда «чираттагы финанс елына» сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 16 июль
№ 48-ТРЗ